ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г.Казань Боерык

05.11.2020 № 339- од

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 июнендәге 146-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территориясе чикләрендә төзергә, үзгәртеп корырга планлаштырыла торган, капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максаты белән боерам:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 июнендәге 146-од номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 12.12.2019 елның 12 нче декабрендәге 393-од номерлы, , 2020 елның 27 нче апреленнән 128-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне истә тотып), Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территориясе чикләрендә төзергә,

үзгәртеп корырга планлаштырыла торган, капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф. С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 5 нче ноябреннән 339-од номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 июнендәге 146-од номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 12.12.2019 елның 12 нче декабрендәге 393-од номерлы, , 2020 елның 27 нче апреленнән 128-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне истә тотып), Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге махсус саклаңыла торган табигать территориясе чикләрендә төзергә, үзгәртеп корырга планлаштырыла торган, капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 нче бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик һәм физик затлар.»;

1.3.5 пунктының икенче абзацында «мәгълүмат стендларында» сүзләреннән соң «һәм Комитетның рәсми сайтында» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге махсус саклаңыла торган табигый территория чикләрендә төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге, аларның реквизитларын һәм чыганакларын күрсәтеп, Комитетның рәсми сайтында(http://ojm.tatarstan.ru), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган;

1.5 пунктында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кызыл линияләр – гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен билгели торган һәм территорияне планлаштыру документларында билгеләнергә, үзгәртелергә яки гамәлдән чыгарылырга тиешле линияләр»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

төзүче – үзенең җир кишәрлегендә яисә башка хокук иясенең җир кишәрлегендә (дәүләт (муниципаль) милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда, дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча «Росатом» дәүләт корпорациясе, Галәм

эшчәнлеге буенча «Роскосмос» дәүләт корпорациясе, дәүләти бюджетныкы булмаган фондларның идарә органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең бюджет законнарында билгеләнгән очракларда, килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (муниципаль) заказчысы вәкаләтләрен яки « Төзүчеләрнең бөлгенлеккә төшү очрагында өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча ачык - хокукый компания турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы нигезендә, килешүләр нигезендә, үзләренең төзүче функцияләрен тапшырган) капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны, аларга капиталь ремонт ясауны, сүтүне, шулай ук инженерлык эзләнүләрен башкаруны, аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өчен проект документларын әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат. Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен, техник заказчыга тапшырырга хокуклы»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында»гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр округы яки яки шәһәрдә (авыл җирлегендә) төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза астында дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгать аңлашыла («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 ст.1 п.). Гаризаларның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентның 1,2,3 нче кушымталарында китерелгән.»;

2 нче бүлектә:

2.1 пункттагы «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 ст. 5 бүлеге (алга таба - РФ ШтК);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре»15.12.2017ел, 996 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 996 нчы карары белән расланган нигезләмә);

2.5 пунктында:

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графының 2 пунктындагы унынчы-

унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору эшләре башкарыла торган, (РФ Штк 49 статьясындагы 5 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәү өлешендә) проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсе, шул исәптән, әгәр әлеге проект документациясе белән, линияле объектларны да кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган булса (РФ Штк 48 статьясындагы 12.1 өлешендә каралган очракта,төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр мондый проект документларына РФ ШтК 49 статьясы нигезендә экспертиза үтәргә тиеш булса, РФ ШтК 49 статьясындагы 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ ШтК 49 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

6) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан тапшырылган һәм РФ ШтК 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, аның белән җәлеп ителгән, проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча белгеч тарафыннан расланган, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ ШтК 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында:

«729нчы номерлы карар» сүзләрен «Төзелешкә рөхсәт бирү һәм файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 27 сентябрендәге 729 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

«РФ ШтК 51 ст. 4.21.14 б.» сүзләрен «РФ ШтК 51 ст. 21.14 б.» сүзләренә алмаштырырга;

2.6. пунктында:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына куелган таләпләр исеме» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган оешмалар карамагында булган, шулай ук мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә алу ысуллары; аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар, шул исәптән сервитутны билгеләү турында килешү, гавами сервитутны билгеләү турында карар, шулай ук аның нигезендә күрсәтелгән җир кишәрлеге оештырылган һәм РФ ШтК

57.3 статьясындагы 1.1 өлешендә каралган очракта, әгәр РФ ШтК 51 статьясындагы 7.3 өлешендә башкасы билгеләнмәгән булса, аның нигезендә җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы бирелгән җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен кадастр планында урнаштыру схемасы»;

түбәндәге эчтәлекле 10 нчы пункт өстәргә:

«10) Дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яисә муниципаль җир контроле кысаларында төзелеш, үзгәртеп кору эшләре башланмаган очракта, мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга яки дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы тарафыннан әлеге эшләрнең башлану турында хәбәрнең булмавы турындагы мәгълүмат, әгәр мондый хәбәр җибәрү РФ ШтК 52 статьясындагы 5 өлеше таләпләренә туры китереп мәҗбүри булса, төзелеш, үзгәртеп кору эшләре башкарыла башлау турында гариза бирелгән көнгә үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат. Комитет әлеге мәгълүматны, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакыты озайтуга бәйле рәвештә, төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза биргән очракта, тиешле дәүләт хакимияте органыннан яки җирле үзидарә органыннан соратып ала.»;

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда, аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирдертү, гамәл кылдырту;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы, документларны һәм мәгълүматны бирдертү;

№ 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны бирдертү.»;

2.8 пунктның «Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

1. Төзелешкә рөхсәт бирүдә:

1) РФ Штк 51 статьясындагы 7 өлешендә каралган документлар булмаганда яки тапшырылган документлар капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәтнамә бирү датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәсә, яисә линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә туры килмәсә (төзелеш өчен рөхсәт булган

очраклардан тыш), линияле объектны үзгәртеп кору (территорияне планлаштыру), шулай ук җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән көнгә гамәлдә булган чикләүләр, рөхсәт ителгән төзелешнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләр буенча документлар әзерләү таләп ителми;

2) РФ Штк 51 статьясындагы 11.1 өлешендә каралган очракта, федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органыннан кергән, төзелеш объектының проект документларының бүлегенең тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының архитектур чишелешләренә туры килмәве турында бәяләмә булганда;

3) төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә яки территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру буенча документ булмаганда (территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән очрактан тыш), әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору җирле үзидарә органы тарафыннан төзелгән территорияне үстерү турында карар кабул ителгән территориядә планлаштырылса, яисә территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән булса.».

2. рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту турындагы гаризадан тыш, төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертүдә:

1) җир кишәрлегенә хокук күчүе, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы, җир кишәрлеген төзү турында хәбәрнамәдә РФ Штк 51 статьясының 21.10 статьясындагы 1 - 4 пунктларында каралган документларның реквизитлары булмау яисә РФ Штк 51 статьясындагы 21.13 өлешендә күрсәтелгән очракта, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документ булмау яки РФ Штк 51 статьясындагы 7 өлешендә каралган документлар булмау.;

2) җир кишәрлегенә, җир асты байлыкларыннан файдалану, җир кишәрлеген төзү хокукыны. Күчүе турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес булмавы;

3) РФ Штк 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган очракта, оештырылган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү датасына, капиталь төзелеш объектының планлаштырылган урнашуы капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруга карата куелган таләпләргә туры килмәве. Шул ук вакытта җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы РФ Штк 51 статьясындагы 21.10 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәргәнчегә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәскә тиеш;

4) урнаштыру планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза кергән очракта, бары тик мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә генә үзгәрешләр кертү турындагы гаризадан тыш, төзелешкә рөхсәт алу яки шәһәр төзелеше планын

төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү өчен бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата куелган таләпләргә туры килмәве. Төзүгә рөхсәт алынганнан соң, бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзү рөхсәтенә үзгәрешләр кертү өчен бирелгән очракта, мондый шәһәр төзелеше планы төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза җибәргәнчегә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәскә тиеш;

5) РФ ШтК 51 статьясындагы 21.7 өлешендә каралган очракта яисә төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында төзүче гаризасы кергән очракта, планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән һәм (яки) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул ителгән көнгә гамәлдәге чикләүләргә туры килмәве;

6) төзүченең төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турындагы гаризасы кергән очракта, планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын урнаштыру рөхсәт ителгән төзүнең, үзгәртеп коруның чик параметрларыннан тайпылу рөхсәтендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

3. төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтуда:

1) рөхсәтнең гамәлдә булу срогы озайтылуга бәйле рәвештә төзүгә бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза биргән көнгә, Комитетта дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге һәм муниципаль җир контроле кысаларында төзү, үзгәртеп кору буенча башланган эшләр булмау факты турында мәгълүмат булу яки әгәр мондый хәбәр җибәрү РФ ШтК 52 статьясындагы 5 өлеше таләпләре нигезендә мәҗбүри булса, дәүләт төзелешен күзәтү органының әлеге эшләрнең башлану турында хәбәрнең булмавы турында мәгълүматы булмавы.

2) төзелешкә рөхсәт бирү вакыты чыкканчы 10 эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә гариза бирү»;

2.12 пунктта:

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү вакытының максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы;

2.14 пунктында:

«Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү, янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган комитетның бинасында һәм бүлмәләрендә тормышка ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа

мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен җайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляскадан һәм этләрдән файдалана торганнарга, бинадан һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;

Комитет территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Комитет бинасына керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның чикләүләрен исәпкә алып, биналарга, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүгә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүматларны  җайлы итеп урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм язма мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Озатучы этнең  махсус укытуын раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»  2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган форма һәм тәртиптә бирелә һәм махсус укытуны раслый торган документ булган очракта, бинага һәм бүлмәләргә, озатучы этне кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт алырга комачаулаучы киртәләрне үтәргә  ярдәм итү».

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы»;

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

3 нче бүлектә:

3.1.1 пунктының 4 һәм 5 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) төзелешкә рөхсәт әзерләү, төзелешкә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү, шул исәптән төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту (алга таба – Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) зарурлыгына бәйле рәвештә, яисә төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында хат, шул исәптән төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайту зарурлыгына бәйле рәвештә (алга таба – баш тарту турында хат);

5) гариза бирүчегә Рөхсәт бирү (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат бирү;»;

3.3.2 пунктының өченче абзацында «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче » сүзенә алмаштырырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Рөхсәтне (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатны әзерләү.»;

3.5.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Әйдәп Баручы Киңәшче:

әлеге регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерә;

мөрәҗәгать итүчедән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалардан кергән документлар нигезендә:

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат әзерли;

Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатны Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрелгән Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат.»;

3.5.2 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.2. Бүлек башлыгы Рөхсәтне (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатны килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имзага җибәрә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: Комитет рәисенә кул куюга юнәлдерелгән Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат.»;

3.5.3 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Комитет рәисе Рөхсәткә (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатка кул куя һәм аны Бүлеккә җибәрә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: имза куелган Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат.»;

3.6 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Рөхсәтне (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатны бирү.»;

3.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.1. Бүлек белгече Рөхсәтне (үзгәрешләр кертүне) яки баш тарту турында хатны бирелгән рөхсәтләр журналында һәм реестрында терки (әлеге Регламентка 4 нче кушымта).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура комитет рәисе тарафыннан Рөхсәткә (үзгәрешләр кертү) яисә баш тарту турында хатка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту

турында хат.»

3.6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Бүлек белгече:

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында, Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яисә баш тарту турында хат алу датасы һәм вакыты турында хәбәр итә;

төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге Регламентта каралган алдагы процедураны тәмамлаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрү.»;

3.6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкаләтле вәкиленә) рәсмиләштерелгән Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хатны Журналда имза куйдыртып бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән Рөхсәт (үзгәрешләр кертү) яки баш тарту турында хат.»;

4 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары»;

5нче бүлектә:

5.1 пунктта «Комитетка» сүзеннән соң «Комитет рәисенә» сүзләрен өстәргә;

5.3. пунктның икенче абзацында «почта аша,» сүзләреннән соң «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, » сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда), яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

*«5.7.* Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1)шикаять, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм аның теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивлаштырылган җавап җибәрелә.

Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать

итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

1 нче, 2 нче, 5 нче, 6 нчы номерлы кушымталарга нумерацион башламнан соң «Форма» сүзен өстәргә;

Регламентның кушымтасында (белешмә өчен) «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты» сүзләренә алмаштырырга.